РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 43 2018 елның 28 ноябре

# Түбән Кама шәһәр Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 31нче карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Салым кодексының 12 маддәсе, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче кисәгенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 31нче карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 карарның 2 пунктындагы 2 пунктчасында «фатирлар» сүзеннән соң «, фатир өлешләре» сүзләрен өстәргә;

1.2 карарның 2 пунктындагы 3 пунктчасында «торак йортлар» сүзеннән соң «, торак йортларның өлешләрендә» сүзләрен өстәргә;

1.3 карарның 2 пунктындагы 3 пунктчасында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 карарны түбәндәге эчтәлекле 2.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.2. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның өлеше яки бүлмә, торак йорт яки торак йортның өлеше;

2) мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган гараж яки машина урыны.

Салым ташламасы, салам түләүче сайлавы буенча салым ташламаларын куллану нигезләренең күләменә карамастан, гаиләгә туры килә торган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Яшәү урыны буенча теркәү урыны Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге булган, салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүчеләр тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә салым түләүчегә салым ташламасы бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланылган салым чоры булып торган елның 1 ноябренә кадәр салым органына тапшырыла.

2. Түбән Кама шәһәр Советының 2018 елның 16 маендагы 24нче номерлы «Түбән Кама шәһәр Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 31нче номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көненнән үткән бер айдан да иртәрәк түгел.

Әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларының гамәлдә булуы 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин